ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

***Карар*** ***Карар***

**_12.11.2025_** **Чистай шәһәре** **№ _544_**

«2026 елга Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
гомуми белем бирү оешмаларында
укучыларны кайнар тукландыруны
оештыру турында»

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 - ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында»РФ Президентының 2024 елның 23 гыйнварындагы 63 номерлы Указы, «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта белем бирү программалары буенча укучыларны туклану белән тәэмин итү хакы нормативын раслау турында» 2025 елның 03 октябрендәге 787 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары, «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучыларны түләүсез кайнар туклану белән тәэмин итүгә 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучыларны кайнар туклануның уртача хакын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 22 сентябрендәге 726 номерлы карары, Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының «Халыкның җәмәгать туклануын оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр» 2.3/2.4.3590-20 СанПиНның санитар-эпидемиологик кагыйдәләрен һәм нормаларын раслау турында» 2020 елның 27 октябрендәге 32 номерлы карары, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Белем алуы Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары тарафыннан өйдә оештырылган сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны ике тапкыр түләүсез туклану белән тәэмин итү тәртибен, шул исәптән ике тапкыр Түләүсез туклануны акчалата компенсация белән алыштыру мөмкинлекләрен раслау турында» 2023 елның 01 февралендәге под-183/23 номерлы боерыгы нигезендә, халыкка социаль ярдәм күрсәтү һәм укучыларның сәламәтлеген ныгыту максатларында, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә:

1.1. 2026 уку елына Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы укучылары өчен, «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларны башлангыч гомуми белем бирүне оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына мәгариф программалары буенча белем алучыларны кайнар тукландыруның уртача бәясен билгеләү хакында» 2025 елның 22 сентябрендәге 726 номерлы карары нигезендә бер укучыга бер укучыга көн саен 77 сум 76 тиен исәбеннән түләүсез кайнар туклану оештырырга;

1.2. 2026 елга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2026 елга, 2027 һәм 2028 елларга план чорына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта белем бирү программалары буенча укучыларны туклану белән тәэмин итү хакы нормативын раслау турында» 2025 елның 03 октябрендәге 787 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы шәһәр һәм авыл гомуми белем бирү оешмаларының 5-11 сыйныфлары укучыларын бер укучыга көн саен 10 сум 70 тиен күләмендә субсидияләр акчалары исәбеннән тукландыруны оештырырга;

1.3. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының муниципаль мәгариф оешмалары тарафыннан укулары өйдә оештырылган сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар өчен, шул исәптән ике тапкыр түләүсез туклануны акчалата компенсация белән алыштыру мөмкинлеге булган укучылар өчен, шулай ук социаль ярдәмгә мохтаҗ укучылар өчен, бер укучыга көн саен 35 сум исәбеннән кайнар туклану оештырып, ташламалы туклануны кушымта нигезендә күздә тотарга;

1.4. Гомуми белем бирү учреждениеләренең 5-11 сыйныфларында өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучылар (алга таба-укучылар) өчен түләүсез кайнар ризык оештырырга, атап әйткәндә:

- җан башына уртача керемнәре Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбән булган, аз керемле гаиләләрдәге балаларга;
- белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада көндезге уку шартларында өлкән бала 18 яшькә җиткәнчегә кадәр яисә 23 яшькә җиткәнчегә кадәр, җан башына уртача керемнәре Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбән булган күпбалалы гаиләләрдән булган балаларга;
- социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдәге балаларга.

Социаль ярдәм чаралары 5-11 сыйныф укучылары өчен уку чорында көн саен бер тапкыр кайнар туклану рәвешендә күрсәтелә (1 нче кушымта).

Әлеге чара акчалата компенсация яки азык-төлек җыелмасы белән алмаштырыла алмый.

Гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларга түләүсез туклану бирү турындагы карар баланың законлы вәкилләреннән социаль ярдәм чаралары күрсәтү турындагы гариза нигезендә мәктәп комиссиясе тарафыннан кабул ителә.

1.5. Укучыларны тукландыруны оештыруга муниципаль заказ урнаштырганда заказчы булырга;

1.6. Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртип һәм күләм нигезендә һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматлар нигезендә социаль тәэмин итүнең Бердәм дәүләт мәгълүмат системасыннан (алга таба - ЕГИССО) файдалану юлы белән белем алучыларны тукландыруны оештырганда ташламалар бирү турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

2. Чистай муниципаль районының финанс-бюджет палатасында (Н.А. Карманова) азык-төлекне үз вакытында финанслауны һәм акчаларның максатчан кулланылышын тикшереп торуны тәэмин итәргә;
3. Мәктәп ашханәләрен һәм азык-төлек товарлары, үзләре җитештергән продукция белән буфетларны тәэмин итүче предприятиеләргә һәм индивидуаль эшкуарларга контрактлар шартларын үтәргә тәкъдим итәргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының (https://chistopol.tatarstan.ru) рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.
6. «2026 елның беренче яртыеллыгына Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны кайнар тукландыруны оештыру турында» 2025 елның 30 октябрендәге 538 номерлы карарны үз көчен югалткан дип танырга.
7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең мәгариф буенча урынбасары - Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгына (О.В. Купцова) йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов